# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# «ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

«6» апрель 2015 ел № 36/8

**Аерым категориядәге затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру тәртибе**

Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында» 2009 елның 18 маендагы 559 номерлы Указы, Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 8 июлендәге «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре» 613 номерлы Указы, Тукай районы прокуратурасының 2015 елның 02 мартындагы 02-08-03 номерлы тәкъдиме нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Аерым категориядәге затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру тәртибен расларга.
2. «Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Тукай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне урнаштыру тәртибе хакында» 2011 елның 22 февралендәге 3/14 номерлы Тукай районы Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе В.Г. Хаҗиев